| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**09.03.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№474** |

Зеленодольск муниципаль районының эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2008 елның 15 маендагы «Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда административ чикләүләрне бетерү буенча кичектергесез чаралар турында» 797нче номерлы Указын, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне координацияләү эшен оештыру максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районының эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы турында» 2518 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы составына Зеленодольск шәһәрендәге «Үсеш партиясе» бүлекчәсе җитәкчесе Абдуллина Регина Ренатовнаны кертергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Зеленодольск муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев